**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЧИРПОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422615 с. Чирпы,
ул. Заводская, д.22
тел: 8 (84378) 2-91-45
E-mail: Chirp.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧИРПЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422615 Чирпы авылы,
Завод урамы, 22 йорт,
тел: 8 (84378) 2-91-45
E-mail: Chirp.La@tatar.ru

---

**2024 елның 5 феврале** **4 номер**

# КАРАР

## 2024-2028 елларга Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлеге территориясендә гражданнарның шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуның яңа электрон хуҗалык кенәгәләрен булдыру һәм алып бару турында

"Шәхси ярдәмче хуҗалык турында" 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясына ярашлы, Россия Федерациясенең 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законы, Россия Федерациясе авыл хуҗалыгы министрлыгының «хуҗалык кенәгәләрен алып бару формасын һәм тәртибен раслау турында» 2022елның 27 сентябрендәге 629 номерлы боерыгы белән, һәм «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алу максатларында Чирпы авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Лаеш муниципаль районының Чирпы авыл җирлеге территориясендә агросәнагать комплексына ярдәм итү өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең бухгалтерлык һәм махсуслаштырылган хисаплылыгы, җыю һәм җыелма хисапларны формалаштыру, субсидияләрне мониторинглау, исәпкә алу, контроль һәм анализлауны, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең комплекслы җыю һәм эшкәртү мәгълүмати системасын кулланып шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуны эшкәртүнең электрон формадагы 2024 - 2028 еллар чорына яңа кенәгәсен оештырырга.

2. Һәр ел саен, 1 гыйнварга шәхси ярдәмче хуҗалыкларны тулаем урап узу һәм шәхси ярдәмче хуҗалык әгъзаларыннан сораштыру юлы белән 10 гыйнвардан 15 февральгә кадәр кенәгәләрдә күрсәтелгән мәгълүматларны җыюны гамәлгә ашырырга.

3. Хуҗалык китапларына язмаларны шәхси ярдәмче хуҗалык башлыгы яки шәхси ярдәмче хуҗалыкның башка әгъзалары тарафыннан ирекле нигездә бирелгән мәгълүматлар нигезендә ясарга.

4. Хуҗалык кенәгәләрен алып барганда хуҗалыкны алып баручы гражданнар биргән мәгълүматның конфиденциальлеген, аның саклануын һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә яклауны тәэмин итәргә кирәк.

5. Хуҗалык кенәгәләрен билгеләнгән тәртиптә алып бару һәм аларның саклануы өчен җаваплы итеп Чирпы авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре билгеләнә.

6. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам

**Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Чирпы авыл җирлеге**
**башкарма комитеты җитәкчесе**
**вазыйфаларын башкаручы** **Зотин Р.Ю.**